РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИХАЙЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИХАЙЛОВКА ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР №1**

Михайловка авылы 06 июль 2026 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының "Михайловка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына керүче Удобновка авылын бетерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында»**

Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлегендә яшәүчеләрнең Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Михайловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Удобновка авылын бетерү мәсьәләсе буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 елгы 33-ФЗ номерлы Федераль законга, Михайловка авыл җирлеге Уставына таянып, «Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәсе белән,

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Михайловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Удобновка авылын бетерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында: Михайловка һәм Элемтә авылларында, шулай ук Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында 2026 елның 7 июльдан да соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Билгеләү:

1) гавами тыңлауларны үткәрү вакыты – 2026 елның 23 июль, 10.00 сәгатьтә;

2) үткәрү урыны-ТР, Мөслим районы, Михайловка авылы, Гагарин ур., 1 йорт (Михайловка авылы урта белем бирү мәктәбе бинасы);

3) фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла, чыгыш ясау хокукы булган гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирелә торган адрес: ТР, Мөслим районы, Михайловка авылы, Ленин ур., 15 йорт (эш көннәрендә-8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр);

4) чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризаларны 22 июльга кадәр бирү срогы;

4. Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге башкарма комитетына билгеләнгән тәртиптә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда Михайловка һәм Элемта авыллары халкы катнашында «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» Михайловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Удобновка авылын бетерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

5. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Михайловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Удобновка авылын бетерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында»2025 елның 8 августындагы 1 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Михайловка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Н.А. Ращупкина